**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 июль № 506

г. Казань

2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен;

2016 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\506.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 июль, 506 нчы карары белән расланды

2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче
эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру
тәртибе

1. Әлеге 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү» ярдәмче программасы нигезендә, өлкән яшьтәге затларның дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү максатларында эшләнде һәм 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен билгели.

2. 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны Татарстан Республикасы территориясендә оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр арасыннан 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту чараларын тормышка ашыру өчен җаваплы дәүләт казна учреждениесен (алга таба – учреждение) һәм учреждениенең 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту чараларын тормышка ашыру буенча вазыйфаларын билгели.

3. 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту чараларын финанслау түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла:

2016 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программаларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды

бюджетыннан субсидия исәбеннән;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән.

4. Әлеге Тәртип нигезендә Татарстан Республикасында яшәүче, 55 яше тулган хатын-кыз һәм 60 яше тулган ир-ат эшләмәүче пенсионерлар түләүсез нигездә компьютер белеменә укырга хокуклы.

5. Эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту программасы түбәндәге темаларны өйрәнүне күздә тота:

персональ компьютерлар турында белешмәләр;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, электрон почта һәм тавышлы аралашу чаралары белән эшләү турында белешмәләр;

WINDOWS операцион системасында эшләүнең төп принциплары;

Microsoft Word текст редакторыннан файдаланунық төп принциплары;

мәгълүмат киоскларыннан, түләү терминалларыннан файдалану, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләрен алу мөмкинлекләре турында белешмәләр.

6. Компьютер белеменә укыту дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендәге контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә учреждение эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту хезмәтләре күрсәтү хакында дәүләт контракты (алга таба – дәүләт контракты) төзегән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган мәгариф оешмасы (алга таба – мәгариф оешмасы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Компьютер белеменә укытуга керү өчен эшләмәүче пенсионер (алга таба – гариза бирүче) 2016 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча мәгариф оешмасына, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык биреп, кәгазьдә яки электрон рәвештә ирекле формада компьютер белеменә укыту турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

пенсия таныклыгы күчермәсе яисә Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан пенсия алу фактын раслаган белешмә;

шәхесне таныклый торган документ күчермәсе;

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (булган очракта).

8. Гариза бирүчеләрне компьютер белеменә укырга кабул итү бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән гаризаларны һәм документларны кертү буенча чират тәртибендә һәм әлеге максатларга бүленгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

9. Гариза бирүчегә компьютер белеменә укыту буенча белем бирү хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гариза бирүченең әлеге Тәртиптәге 4 нче пункт таләпләренә туры килмәве;

гариза бирүченең бу Тәртиптәге 7 нче пунктның өченче – бишенче абзацларында каралган документларны тапшырмавы;

гариза бирүченең дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыруы.

10. Мәгариф оешмасы төзелгән дәүләт контракты нигезендә:

массакүләм мәгълүмат чаралары аша Татарстан Республикасы халкына компьютер белеменә укытуга хокуклары турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

гаризалар кабул итүне һәм аларны кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра;

гариза теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә компьютер белеменә укыту буенча белем бирү хезмәтен күрсәтү һәм уку төркемен төзү өчен гариза бирүчене гражданнар исемлегенә кертү турында яки әлеге белем бирү хезмәтен күрсәтүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән юл белән гариза бирүчегә кабул ителгән карары турында хәбәр итә;

компьютер белеменә укыту буенча белем бирү хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән гариза бирүчеләр исемлеген һәм алар арасыннан уку төркемнәре төзи;

укулар башланганчы ун эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә аны уку төркеменә кертү турында, укытуны үткәрү көне, вакыты һәм урыны хакында гаризада күрсәтелгән юл белән хәбәр итә;

дәүләт контрактында каралган мәгариф программасы нигезендә укыту үткәрә;

уку тәмамланган көнне, мәгариф программасында билгеләнгән күләмдә укуны уңышлы тәмамлаган шарт белән эшләмәүче пенсионерга укыту үтү турында билгеләнгән үрнәктәге документны бирә;

учреждениегә дәүләт контрактында билгеләнгән тәртиптә, рәвешләрдә һәм вакытларда, әмма 2016 елның 24 декабреннән дә соңга калмыйча, уку үткән һәм укуны үтү турында билгеләнгән үрнәктәге документлар алган эшләмәүче пенсионерлар саны турында мәгълүмат (белешмәләр) тапшыра.

12. Компьютер белеменә уку үтү өчен башка җирлеккә баруга һәм уку чорында башка җирлектә торуга эшләмәүче пенсионерның тотылган акчасын түләү яки чыгымнарын компенсацияләү эшләмәүче пенсионерның шәхси акчасы исәбеннән башкарыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 июль, 506 нчы карары белән расланды

2016 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибе

1. Әлеге 2016 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын (алга таба – социаль программа) тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия фонды акчасыннан нәтиҗәле һәм максатчан файдалану максатларында эшләнде 2016 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне (алга таба – субсидия) тоту тәртибен билгели.

2. Субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган бердәм счетка күчә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан Субсидия килү турында мәгълүмат алганнан соң, өч эш көне эчендә Казначылыкка 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына (алга таба – вәкаләтле орган) финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгымнар исемлеген тапшыра

4. Вәкаләтле орган, счетына субсидия килгәннән соң, биш эш көне эчендә Казначылыкка вәкаләтле орган тарафыннан 2016 елда Татарстан Республикасында

яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту чараларын тормышка ашыру оештыру вазыйфалары йөкләнгән, вәкаләтле орган ведомствосы буйсынуындагы учреждениегә (алга таба – учреждение) финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгымнар исемлеген тапшыра.

5. Акча киләчәктә учреждение белән мәгариф оешмасы арасында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендәге контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту хезмәтләре күрсәтү турында дәүләт контракты (алга таба – дәүләт контракты) нигезендә мәгариф оешмасы күрсәткән хезмәтләргә түләү өчен вәкаләтле орган тарафыннан учреждениенең Казначылыкта ачылган шәхси счетына күчерелә.

6. Учреждение ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 сына кадәр вәкаләтле орган билгеләгән формалар буенча һәм вакытларда вәкаләтле органга эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту чараларын тормышка ашыруга Субсидия исәбеннән чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

7. Вәкаләтле орган ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Пенсия фонды билгеләгән тәртиптә һәм формалар буенча, социаль программаны финанслашу буенча йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлүен раслаган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

8. Вәкаләтле орган һәм учреждение тапшырылган хисап белешмәләренең дөреслеге һәм субсидиядән нәтиҗәле һәм максатчан файдаланган өчен законнар нигезендә җавап тоталар.

9. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия вәкаләтле орган тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

10. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү үткәрә.

11. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидиядән максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә башкара.

12. Учреждениегә бирелгән һәм максатчан файдаланылмаган субсидия вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң 10 көн эчендә аның Казначылыктагы шәхси счетына кире кайтарылырга тиеш.

Учреждение акчаны кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозганда, вәкаләтле орган кайтару вакыты узган көннән соң биш көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

13. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә үзенең Казначылыктагы шәхси счетына кергән акчаны күрсәтелгән акча кергән мизгелдән

соң ике эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылыктагы шәхси счетына күчерүне тәэмин итә.

14. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өч эш көне эчендә субсидияне Россия Федерациясе Пенсия фондына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

F:\KARAR\2016\506_2.docx